ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

КАРАР

“12” ноября 2019 ел №142

**Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында**

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерү мәсьәләләрен хәл итү максатларында, «Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче затларны социаль тернәкләндерү эшчәнлеген оештыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 29 июлендәге 631 номерлы карары нигезендә **КАРАР БИРӘМ**:

1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзергә.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларын социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча ведомствоара муниципаль комиссия турында Нигезләмәне (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларын социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия составын (2 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларын социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссиясенә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советы аппараты җитәкчесе Р.Н.Галимуллинга йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы И.Г.Нуриев

Арча муниципаль районы
башлыгының 2019 елның 12
ноябрь 142 номерлы карарына
1 нче кушымта

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча ведомствоара муниципаль комиссия турында
Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба-Ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгы каршындагы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган даими эшләүче килештерү органы булып тора.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерүгә ярдәм күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмәгә таяна.

1.3. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге социаль тернәкләндерүгә ярдәм итү күздә тотыла торган затларның теләк белдерүләре ирекле лек һәм ихтыярлылык принципларына нигезләнә.

## II. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары

Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җаваплылыгына тартылган һәм (яки) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга, шул исәптән җинаять-хокукый характердагы җинаять җәзасына дучар булган затларны җәмгыятькә яңадан яраклаштыру максатларында социаль-икътисадый, педагогик, хокукый характердагы чаралар комплексын гамәлгә ашыру:

пенитенциар ярдәм күрсәтү;

һөнәри юнәлеш бирү һәм хезмәткә яраклаштыру;

торак ягыннан һәм көнкүрештә урнаштыру;

медицина ярдәме күрсәтү;

психологик ярдәм итү;

югалган туганлык һәм башка социаль элемтәләрне торгызуда булышлык күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерүнең башка формалары.

2.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, гражданлык җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлеген килештерүне һәм аларның иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның Республика регистрының муниципаль сегментын алып бару.

2.4. Кабат (рецидив) җинаятьчелекне кисәтү.

2.5. Җәмәгатьчелеккә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерү һәм хезмәткә кертеп җибәрү буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә алып барыла торган эш турында мәгълүмат бирү.

## III. Ведомствоара комиссия вәкаләтләре

Йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында, Ведомствоара комиссия түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

3.1. Шәхси тәртиптә социаль тернәкләндерүгә ярдәм күрсәтүгә ризалык биргән затларның социаль хәлен карый һәм анализлый.

3.2. Законда каралган дәүләт һәм муниципаль ярдәм механизмнарын, башка оешмаларның һәм гражданлык җәмгыяте институтларының мөмкинлекләрен исәпкә алып, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затны социаль тернәкләндерүнең шәхси программасын эшли. Тернәкләндерү программасында каралган һәр чараны тормышка ашыру өчен җаваплы затларны, аларны тормышка ашыру вакытын билгели.

3.3. Социаль тернәкләндерү буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәләрен һәм нәтиҗәлелеген анализлый.

3.4 Түбәндәге очракларда шәхси социаль тернәкләндерү программасын тормышка ашыруны туктату турында карар кабул итә:

тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешкәндә;

зат Арча муниципаль районыннан читкә даими яшәү урынына киткәндә (Зат Татарстан Республикасы чикләрендәге башка муниципаль районга киткән очракта, затка карата әлеге факт турындагы мәгълүмат, булган материаллар белән бергә Татарстан Республикасының әлеге муниципаль районы ведомствоара комиссиясенә җибәрелә);

затның социаль тернәкләндерүдән баш тарту турында гаризасы керү;

алга таба шәхси социаль тернәкләндерү программасын гамәлгә ашыру мөмкинлеген юкка чыгара торган башка очракларда.

3.5. Арча муниципаль районында кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазыйфаи затларга җибәрә.

3.6. Ведомствоара комиссия хокуклы:

3.6.1. Үз компетенциясе кысаларында Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар һәм гражданлык җәмгыяте институтлары тарафыннан үтәлешкә тәкъдим ителгән карарлар кабул итәргә;

3.6.2. Җинаять җаваплылыгы яки административ җаваплылыкка тарта торган закон бозу билгеләре ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту

турындагы мәсьәләне хәл итү өчен, хокук саклау органнарына тиешле документлар һәм материаллар җибәрергә.

3.7. Ведомствоара комиссия үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

3.7.1. Россия Федерациясе җәзаларны үтәү Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе белән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу мәсьәләләре буенча;

3.7.2. Эчке эшләр органнары белән:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

шәхси профилактик эш үткәрү;

хокукый белемнәрне алга сөрүдә катнашу;

3.7.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм аңа караган учреждениеләр (социаль яклау бүлекләре, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре) белән:

«Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законны һәм "Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контакт нигезендә, күрсәтү турында" 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын тормышка ашыру кысаларында, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга матди ярдәм күрсәтү;

билгеле яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасыннан социаль хезмәт алучылар белән профилактик эш алып бару;

социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән балигъ булмаган балаларны, шулай ук иректән мәхрүм итү белән бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән балигъ булмаган гражданнарны социаль адаптацияләү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителергә әзерләнүче затларга хезмәт базары, вакансияләр булу турында мәгълүмат бирү юлы белән яңадан социальләштерүгә ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга, эшчәнлек өлкәсе (һөнәр) сайлау, эшкә урнашу, һөнәри белем алу максатларында, һөнәри юнәлеш бирү буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган әлеге категория затларга –эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, эшсез гражданнарга хезмәт базарында социаль яраклашу, һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

ирекән мәхрүм итү урыннарыннан чыккан гражданнарга туры килерлек эш эзләүдә ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны эшкә урнаштыручыларны кызыксындыру;

3.7.4. Беренчел медик-санитар ярдәм оештыру, профилактик һәм диспансер күзәтүен оештыру мәсьәләләре буенча сәламәтлек саклау оешмалары белән, сәламәтлек саклау территориаль идарәсе белән (булган очракта);

3.7.5. Компетенциясе нигезендә дәүләт хакимиятенең бүтән органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, гражданлык җәмгыяте институтлары белән.

## IV. Ведомствоара комиссияне төзү тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

Ведомствоара комиссия рәисе:

Ведомствоара комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә;

Ведомствоара комиссия утырышларын алып бара, хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия;

Ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышы көн тәртибен раслый;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына үз вәкаләтләре кысаларында йөкләмәләр бирә;

Ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителгән документларга кул куя;

Ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Ведомствоара комиссия сәркатибе:

Ведомствоара комиссия рәисе күрсәтмәләрен үти;

Ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен килештерә, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга Ведомствоара комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарына затның тиздән азат ителүе, торагы булу-булмау, эшкә сәләтлелеге, булган һөнәрләре турында җәза үтәү системасы учреждениеләре администрацияләреннән кергән мәгълүматны җыю һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан социаль тернәкләнүгә ярдәм итү турында гаризалар кабул итә;

социаль тернәкләнү программасының һәр катнашучысына озату картасы һәм социаль тернәкләнүнең шәхси программасы чараларын үтәү буенча документлар һәм белешмәләр кертелгән шәхси эш рәсмиләштерә;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның Республика регистрының муниципаль сегментын алып бара;

Ведомствоара комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматны муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан соратып ала;

Ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

Ведомствоара комиссия рәисе күрсәтмәләрен үтәүне, утырышлар нәтиҗәләре буенча мәгълүматлар туплауны оештыра;

Ведомствоара комиссиянең функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы халкына мәгълүмат җиткерүне оештыра.

4:2. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.

4.3. Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, белем бирү оешмалары вәкилләре керә ала (килешү буенча).

4.4. Ведомствоара комиссия составына элек иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, социаль тернәнләндерүнең уңай тәҗрибәсе булган затлар да кертелергә мөмкин.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышларында Арча районы прокуратурасы вәкиле дә катнашырга хокуклы (килешү буенча).

4.6. Ведомствоара комиссия утырышына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Ведомствоара комиссия составына кермәгән дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмалар, гражданлык җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырыла ала.

4.7. Ведомствоара комиссия эшендә катнашу җәмәгать башлангычларында башкарыла.

## V. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эше даими нигездә алып барыла.

5.2. Ведомствоара комиссия утырышлары ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан социаль тернәкләндерүгә ярдәм итү турында кергән гаризалар буенча, ләкин айга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә үткәрелә. Кирәк булган очракта, Ведомствоара комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук Ведомствоара комиссия әгъзасы (рәис белән килештереп һәм Ведомствоара комиссия сәркатибе тәкъдиме буенча) инициативасы буенча Ведомствоара комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.3. Ведомствоара комиссия утырышын Ведомствоара комиссия рәисе алып бара, ул булмаганда яки аның кушуы буенча – Ведомствоара комиссия рәисе урынбасары.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышы вакыты һәм урыны турында социаль тернәкләндерүгә ярдәм итү турында гариза кергзн затларга, аларның туганнарына, утырышларда катнашу максатка яраклы дип табылган башка затларга утырышка кадәр бер тәүлектән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

5.5. Ведомствоара комиссия утырышы вакыты һәм урыны турында Арча районы прокурорына хәбәр ителә.

5.6. Ведомствоара комиссия утырышы анда составының яртысыннан артыгы катнашканда хокуклы була.

5.7. Ведомствоара комиссия карарлары тәкъдим итү характерына ия һәм утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

5.8. Ведомствоара комиссия әгъзалары утырышларда карала торган мәсьәләләр турында фикер алышканда тигез хокукларга ия.

5.9. Утырыш, ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затның теләге буенча, әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча үткәрелә.

5.10. Ведомствоара комиссия әгъзалары комиссия утырышында тикшерелгән мәсьәләләр турында мәгълүматларны әлеге мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка таратырга хокуклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турында мәгълүматларны тараткан өчен Ведомствоара комиссия әгъзалары закон нигезендә җаваплы.

5.11. Ведомствоара комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатында, Ведомствоара комиссия рәисе рөхсәте белән, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүмат бирү рөхсәт ителә.

Арча муниципаль районы
башлыгының 2019 елның 12 _
ноябрь 142 номерлы карарына
2 нче кушымта

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия

**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Нуриев Илшат Габделфәрт улы | - Арча муниципаль район башлыгы, комиссия рәисе; |
| Гарифҗанов Рамил Илгиз улы | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Яруллина Алинә Альберт кызы | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе баш белгече, комиссия сәркатибе; |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Баһавиев Айдар Рашат улы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлек җитәкчесе, полиция полковнигы (килешү буенча); |
| Баһаветдинов Тәлгать Вәлиәхмәт улы | - «Арча РҮХ» ДАССОның баш табибы (килешү буенча); |
| Кадыймова Клара Әгъзәм кызы | - Россия җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Арча районындагы 10 нчы МРУИ ФБУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Гыйбадуллина Гөлфия Мансур кызы | - «Арча районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча); |
| Галәветдинова Ләйсән Нәфыйк кызы | - Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге җитәкчесе (килешү буенча). |